ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 апрель 2023 ел № 3448

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү аның предметы булган муниципаль контрактлар төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 5 августындагы 3745 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясының 6 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү аның предметы булган муниципаль контрактлар төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 5 августындагы 3745 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган срокка концессия килешүләре төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында»;

2) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан

артып китә торган срокка концессия килешүләре төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен кушымтада каралганча расларга»;

3) кушымтада:

- исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган срокка концессия килешүләре төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләре»;

- 1 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен» сүзләреннән соң «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җәмәгать партнеры булган муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр һәм концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелә торган, концедент булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге торган концессия килешүләре,» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлектәге 2.1-2.2 пунктчалар өстәргә:

«2.1. Концедент булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге торган концессия килешүләре Россия Федерациясенең концессия килешүләре турында законнарына туры китереп кабул ителә торган концессия килешүләре төзү турында җирле үзидарә органының муниципаль хокукый акты нигезендә расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган срокка, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясы нигезендә кабул ителә торган муниципаль милекнең капиталь төзелеше объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында муниципаль хокукый актларда каралган акчалар чикләрендә, күрсәтелгән актларда һәм карарларда каралган срокка төзелергә мөмкин.

2.2. Җәмәгать партнеры булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге торган муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр, концедент булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге торган концессия килешүләре Россия Федерациясенең концессия килешүләре турында законнарына туры китереп кабул ителә торган концессия килешүләре, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр төзү турында җирле үзидарә органының муниципаль хокукый акты нигезендә, расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган срокка, муниципаль программалар кысаларында, күрсәтелгән программаларның тиешле чараларында каралган акчалар чикләрендә һәм срокка төзелергә мөмкин.

Әлеге пункт нигезендә муниципаль программа кысаларында төзелә торган муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүнең гамәлдә булуының күздә тотылган срогы күрсәтелгән программаны тормышка ашыру срогыннан артып киткән очракта, муниципаль-шәхси партнерлык турында мондый килешү Россия Федерациясенең дәүләт-шәхси партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык турында законнарына туры китереп кабул ителә торган муниципаль-шәхси партнерлык проектын тормышка ашыру турында муниципаль хокукый акт нигезендә төзелергә мөмкин.

Әлеге пункт нигезендә муниципаль программа кысаларында төзелә торган концессия килешүенең гамәлдә булуының күздә тотылган срогы күрсәтелгән программаны тормышка ашыру срогыннан артып киткән очракта, мондый концессия килешүе Россия Федерациясенең концессия килешүләре турында законнарына туры китереп кабул ителә торган концессия килешүе төзү турында муниципаль хокукый акт нигезендә төзелергә мөмкин.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов